**ГЛАВА**
**Иж-Бобьинского сельского поселения**
**Агрызского муниципального района**
**Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы**
**Әгерҗе муниципаль районы**
**Иж-Бубый авыл җирлеге**
**БАШЛЫГЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

31.10.2025 Иж-Бубый авылы № 2

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы «Иж-Бубый авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Иж-Бәйки торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

Гамәлдәге законнар нигезендә, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендә кабул ителгән «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ номерлы Законның 35 статьясына, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының « Иж-Бубый авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 14 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иж-Бубый авыл җирлеге башлыгы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Иж-Бубый авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Иж-Бәйки торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2025 елның 12 ноябренә 10сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Иж-Бубый авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Иж-Бәйки торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән

(I төркем инвалидлардан, хәрби хезмәттә авыру алган инвалидлардан, 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан, Россия армиясе сафларына хезмәткә чакырылган һәм ирегеннән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучылардан (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгәннәр, ирекleләр) һәм аларның гаилә әгъзаларыннан (бергә яшәүче ата-аналары, ире яки хатыны, балигъ булган балаларыннан) башка), 2026 елда үзара салым акчасын 500 сум күләмендә

кертүгә һәм алынган акчаларны җирлек өчен әһәмияте булган мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтүгә, куллануга ризамы?

1.Иж-Бәйки торак пункт территориясен төзекләндерү ( чүп үләннәрен чабу, юлларны кардан чистарту, тракторны карап тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү, ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу һәм торак пункт территориясен төзекләндерү буенча башка чыгымнар);

2. Су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм башка су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау; сантехник һәм чыгым материаллары, насослар сатып алу, суүткәргеч челтәрен ремонтлау һәм Иж-Бәйки торак пунктында су белән тәэмин итү өчен башка чыгымнар;

3. Иж-Бәйки торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту ( ремонтлау өчен таш сатып алу һәм җәю, автомобиль юлларын карап тоту буенча башка чыгымнар);

“РИЗА” “КАРШЫ”

3. Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Иж-Бәйки авылы, Үзәк урамы, 2нче йорт, авыл мәдәният йорты адресы буенча гражданнар җыенын уздырырга. .

4. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иж-Бубый авыл җирлегенең башкарма комитетына җыенны оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Иж-Бубый авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (http://www.agryz.tatarstan.ru) һәм “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru)

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Ваһапов

Совет Иж-Бобьинского сельского поселения Иж-Бубый авыл җирлеге Советы ИНН 1601002480